**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлегенең Кәрәкәс торак пунктында**
**2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Кәрәкәс торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Кәрәкәс торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- торак пункт эчендәге күперне ремонтлау һәм төзекләндерү.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Бигеш авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге башлыгы** ____________________ **И.Р. Вәлиев**